Республиканский конкурс профессионального мастерства работников сферы воспитания и дополнительного образования «Воспитать человека»

Номинация: «Воспитание классного коллектива»

# Формы воспитательной работы в соответствии с программой воспитания

**Хузина Милауша Рафисовна,**
учитель русского языка и литературы,
классный руководитель 10 класса
муниципального бюджетного
общеобразовательного учреждения
«Большенуркеевская средняя
общеобразовательная школа»
Сармановского муниципального
района Республики Татарстан

2023 год

Я Хузина Милауша Рафисовна, учитель русского языка и литературы и классный руководитель в 10 классе МБОУ «Большенуркеевская СОШ» Сармановского района Республики Татарстан. У меня 33 года стажа, на следующий год будет четвёртый выпускной класс.

В первые годы работы на вопрос «Зачем я выбрала именно эту профессию?» я отвечала: «Конечно же, учить детей». А теперь понимаю: я искала счастье. И хотела научить счастью своих учеников, чтобы они испытывали счастье при общении с окружающими, при созидательном труде и при этом сохранили свою индивидуальность, неповторимость, проявили личность.

Я понимаю, какие высокие требования предъявляются сегодня к результату воспитательной деятельности. Развивающемуся обществу нужны современно образованные, нравственные, предприимчивые люди, которые в ситуации выбора могут самостоятельно принимать решения, способны к сотрудничеству, отличаются мобильностью и динамизмом.

Классный руководитель должен способствовать воспитанию у школьников чувства патриотизма, ценностного отношения к природному и культурному наследию родного края, страны; формировать общечеловеческие нормы гражданской морали (доброты, взаимопонимания, милосердия и терпимости по отношению к людям), культуры общения.

Роль классного руководителя в деле воспитания трудно переоценить. В его обязанности входит не только создание благоприятных условий для личностного развития школьника, но также эффективная помощь в решении психологических проблем, возникающих у ребенка в общении с другими учениками, родителями и учителями. Членами классного коллектива являются не только ученики и классный руководитель, но и родители учеников, поэтому так важно выстроить конструктивные взаимоотношения с родителями, чтобы вовлечь их в классную жизнь. Классный руководитель призван быть связующим звеном между учеником, педагогами, родителями,

социумом, а зачастую и между самими детьми. Триединство «классный руководитель-ученик-родитель» – сильный тандем. Это имеет большое значение в воспитании классного коллектива.

У моих детей хорошая успеваемость, все хорошисты, активисты, постоянные участники школьных и муниципальных олимпиад, конкурсов, соревнований, разных мероприятий.

Воспитательную деятельность я веду по тем направлениям, которые указаны в Программе воспитания. Это гражданское воспитание, воспитание патриотизма; духовно-нравственное развитие и воспитание; эстетическое воспитание; экологическое воспитание; воспитание культуры здорового образа жизни и безопасности; трудовое воспитание; физическое воспитание; познавательное направление воспитания. Чтобы добиться результата, я должна быть всегда в творческом поиске - в поиске новых форм, методов. И тогда мои воспитанники не будут скучать, проявят заинтересованность, смогут раскрыться.

В соответствии с основными направлениями воспитания учащихся, которые я определила для себя и моего классного коллектива, выбираю наиболее эффективные формы работы:

-индивидуальные (беседы, диалоги, разговор по душам);

-групповые (творческие группы);

-коллективные (конкурсы, спектакли, концерты, походы, соревнования).

-тренинги (индивидуальные, групповые).

Конечно, беседы и классные часы остаются привычными формами работы с классом и планируются ещё в начале учебного года. С этого года мы в классе ведём и «Разговоры о важном», которые полюбились как мне, так и детям. Сайт, которым мы пользуемся, предоставляет богатейший презентационный материал и видеоматериалы в совокупности с методическими рекомендациями, которыми можно без труда заинтересовать моих учеников, поскольку они интересуются историей, у них широкий

кругозор и всесторонние интересы. Так, «Разговоры о важном» стали большим подспорьем и в изучении отдельных предметов.

В своей деятельности я стараюсь использовать как традиционные, так и инновационные формы воспитательных практик. Особо хочу выделить педагогику сотрудничества и проектную технологию. Необходимость применения технологии сотрудничества в педагогике вижу в гуманизации отношений, усиления роли человеческого фактора и повышения качества образования и воспитания учащихся на основе инновационных процессов. Педагогика сотрудничества предполагает такой уровень учебно-воспитательного процесса, при котором его объекты и субъекты объединяются в общей деятельности принципами взаимоуважения, взаимопомощи и коллективизма. Основными ее принципами являются взаимодействие, сотрудничество, партнерские отношения, гуманизм, творчество, развитие личности, коллективизм, совместная деятельность, диалог и взаимообогащение. Именно на этих принципах мы организуем акции «Белые цветы», «Георгиевская лента», «Бессмертный полк», над планированием и осуществлением которых работает наша команда. Вызывают интерес у моих детей спектакли — представления, предполагающие демонстрацию выступающими для зрителей целостного театрального действия. Подготовленные нами инсценировки, устные журналы, например, по ономастике, сплотили наш коллектив, позволили выявить скрытые таланты учеников, научили их раскрепощённости, развили артистизм. Каждый раз дети реализовывали себя то как актеры (выступающие), то как зрители.

Я хорошо понимаю и педагогические возможности игры в старшем школьном возрасте: игра способствует активизации познавательной деятельности детей; она носит многофункциональный характер, отражая в своем содержании и структуре особенности реальной профессиональной деятельности; вовлечение в деятельность способствует формированию

адаптивных качеств личности; игра способствует систематизации теоретических знаний, развитию практических умений и навыков.

Такой игрой является ситуационно-ролевая игра. Это специально организованная деятельность, состоящая из ситуационно-ролевых моделей и их внеигрового обеспечения, направленная на подготовку старшеклассников к реализации себя как субъекта социальных отношений. Например, такие игры как «Если бы я был…», «Защита профессии перед родителями», «Обвинитель», «Живое зеркало» и другие позволили развить коммуникативные навыки детей, помогли раскрыться и запомнились им надолго. Кроме того, наш класс, являясь шефом 2 класса, организовал такие же игры и с ними - это «Мусору вторую жизнь», «Коровы, собаки, кошки». Так они приобрели опыт организации мероприятий, научились общаться с детьми младшего звена. Все эти формы работы укрепляют мои отношения с воспитанниками, способствуют сплочению коллектива.

В нашей школе работает краеведческий музей. Привлечение арсенала музейной педагогики помогает мне воспитывать детей, знающих историю малой родины: своего села, района, республики. Ученики проводят экскурсии для учащихся младших классов, выступают в роли экскурсоводов, когда школу посещают делегации. Именно они являются организаторами конкурса по сбору музейных экспонатов, они приводят в порядок музейную документацию. У нас хранятся видеозаписи интервью с последним ветераном из нашего села, их дети периодически просматривают, прослушивают, используют во внеклассной работе.

Также мы работаем над долгосрочным проектом «Мин яратам сине, Татарстан!»(«Я люблю тебя, Татарстан!») Проект рассчитан на 2 года и подразумевает изучение истории, традиций своей семьи с составлением генеалогических древ на первом этапе с выходом на второй и третий этапы, целью которых было изучение истории района и республики, государственных символов, изучение биографии знаменитых людей – выходцев из нашего района и республики Татарстан. При этом учащиеся

защищают мини проекты, создают презентации, которые впоследствии тоже будут использованы во внеурочной деятельности. Проект разработан и конечные продукты тоже оформляются на татарском языке, так как наша цель – сохранение родного языка, воспитание уважения и бережного отношения к нему.

## « *Мин яратам сине, Татарстан!*»

(класс җитәкчесенең тәрбия проекты)

«Мин яратам сине, Татарстан» проекты дәвамлы патриотик тәрбия программасы кысаларында әзерләнгән.

Ул гаилә, туган авыл, район һәм республика тарихын өйрәнүгә юнәлтелгән. Бу проект рамкаларында мәгълүмат туплау, иҗади биремнәр үтәү, гаиләләрнең шәҗәрәләрен төзү, бәйрәм сценарийләре төзү, эти-әниләр белән чаралар үткәрү күздә тотыла.

**1. Проектның максаты:**

1. Балаларда туган илгә, торган җиргә, аның тарихына ярату хисләре тәрбияләү.

2. Ил тарихын үзенең тирә-юненнән табарга, күрергә өйрәтү.

3. Милләтебезнең мәдәни-рухи байлыкларын танырга өйрәтү, кызыксыну уяту. Халкыбызга хас матур сыйфатларны үзләрендә булдырырга омтылыш тәрбияләү.

4. Балаларның иҗади һәм интеллектуаль сәләтләрен үстерү, әдәби телдә сөйләшүләренә ирешү.

5. Туган як табигатенә мәхәббәт тәрбияләү, әдәп-әхлак, нечкә күңеллелек хисләрен табигать аша балаларга җиткерү

**Эшчәнлек формалары:**

- гаилә, авыл урамнары турында мәгълүмат туплау; авыл, район, республика белән бәйле топоним, гидронимнарның килеп чыгышын ачыклау;
- халык бәйрәмнәрен, туган як фольклорын өйрәнү;

- анализлау юлы белән проект нәтиҗәләрен ачыклау.

**2. Проект өстендә эшләү вакыты**

Укучыларның 10-11 сыйныфларда уку чоры (аерым очракларда проектны тормышка ашыру вакыты артырга мөмкин).

**3. Проектның актуальлеге.**

Балачак – үз принциплары, дөньяга үз карашы булган шәхес тәрбияләү чоры. Малай һәм кызлар авыр, кайвакыт аңлашылып бетми торган дөньяда яшәргә өйрәнә. Монда аларга өлкәннәрдән әти-әниләр, укытучылар ярдәмгә килә. Бүгенге безнең биргән белемнәр һәм тәрбия киләчәкне билгели. Шуңа күрә укучыларны төрле чыганаклардан мәгълүмат тупларга, аларны анализларга, проблемаларны хәл итүгә иҗади якын килергә, коллективта эшләргә өйрәтерлек практик эшчәнлеккә җәлеп итү мөһим. Моннан тыш бу проект төрле буын кешеләре белән аралашырга өйрәтүдә дә зур роль уйный. Иң мөһиме: проект буенча әшләү үз илен, халкын яратучы, гореф-гадәтләрне белүче һәм хөрмәт итүче гражданин тәрбияләргә мөмкинлек бирә.

**4. Проектны тормышка ашыру юллары.**

Проект түбәндәге формаларда тормышка ашырылырга мөмкин:

- мәгълүмат туплау һәм анализлау;
- презентацияләр эшләү, очрашулар, әңгәмәләр үткәрү;
- иҗади биремнәр үтәү.

Проект кысаларында Интернет ресурслар, проектор, компьютер, кебек чаралар куллану күздә тотыла.

**5. Проектны тормышка ашыручылар**

10-11 сыйныф укучылары һәм сыйныф җитәкчесе

**6. Көтелгән нәтиҗә:**

Балаларның ил тарихы буенча белемнәре, грамоталык дәрәҗәсе артыр, алар сценарийлар, альбомнар төзергә, карта белән эшләргә, Интернет челтәрендә ориентлашырга өйрәнер, аларның шәхси сыйфатлары үсәр дип көтелә. Проектның төп нәтиҗәсе булып яшь буынга халкыбызның бай

тарихы, мәдәни байлыклары турында мәгълүмат бирү, бу байлыкларны сакларга өйрәтү, балаларда патриотик үзаң тәрбияләү тора.

**7. Чыгымнар.**

Проектның иң зур уңай ягы: бернинди дә өстәмә чыгымнар булмау һәм финанслар таләп ителмәү.

| **МИН ЯРАТАМ СИНЕ, ТАТАРСТАН! (**ПРОЕКТ) |
| --- |
| ТУГАН ЯКНЫ ӨЙРӘНҮ АША БАЛАЛАРДА ВАТАННЫ ЯРАТУ ХИСЛӘРЕ, РУХИ-ӘХЛАКЫЙ БАЙЛЫК ТӘРБИЯЛӘҮ. |

| УКУЧЫЛАРГА ИҖАДИ ЭШ |
| --- |

ЯШЬ ДУС! Син - зур, тарихлы, борынгы нәселле, эшчән, милли рухлы татар баласы. Чал Идел дулкыннарында сөелеп, җырлап хезмәт иткән, батырлар иле булган ТАТАРСТАН баласы булуың белән горурлан!

Түбәндәге биремнәргә җавап әзерлә:

- нәсел җебеңнең очы кайда? Шәҗәрәңне 7 буынга кадәр төзергә тырыш;
- авыл тарихыннан нәрсә беләсең?
- авылның елга-су, басу-болын исемнәрен өйрән;
- Татарстан, Сарман районы, безнең төбәкнең җир асты һәм өсте байлыкларын беләсеңме?
- халкыбызның милли хәзинәләрен өйрән;
- нәрсә ул халык педагогикасы?

- милләтебезне саклап торучы ана телебездә чиста итеп, әдәби телдә сөйләш;
- беренче һәм хәзерге президентларыбыз, дәүләт символлары турынданиләр беләсең?

| Темалар | Максатка ирешү юллары | Ныгыту методлары, формалары |
|---|---|---|
| 1. Мин. Минем исемем. Безнең гаилә. Безнең 7 буын. | Махсус әзерләнгән әңгәмәләр. Шәҗәрәләр. Фотоальбом битләренә сәяхәт. Әти-әниләр, әби-бабайлар белән очрашулар, әңгәмәләр. | Дидактик һәм сүзле уеннар: «Радио», «Исемнәр илендә», «Үзең турында сөйлә», «Могҗизалар кыры» (әти-әниләре белән) |
| 2. Минем авылым, аның исеме. Авыл тарихы. | Экскурсияләр, күзәтүләр. Мәктәп музеендагы материаллар белән танышу. Авыл аксакаллары белән очрашулар. | Экскурсия, күзәтүләрнең нәтиҗәләрен инша, рәсемнәрдә күрсәтүләр. Әдәби әсәрләр, газета материалларын файдалану. |
| 3.Безнең авыл табигате. Елга-су, басу-болын атамалары. | Экскурсияләр, күзәтүләр, шигырьләр, музей материаллары белән танышу. Табышмак, мәкальләр файдалану. Топонимика буенча китаплар, сүзлекләргә мөрәҗәгать итү. | Иллюстрацияләр ясау, шигырьләр, хикәяләр, экиятләр язу. «Әхмәр тау ник унике» (В.Хәйруллина һ.б.). |
| 4. Милли көнкүреш әйберләре, аларның әдәби әсәрләрдә чагылышы. | Музей экспонатлары белән танышу, көнкүреш әйберләренең исемен ике телдә белү, картиналар, иллюстрацияләр буенча әңгәмә. | Г.Тукай, Г.Бәширов, Г Ибраһимов әсәрләреннән өзекләр. «Кич утыру» дигән әти-әниләр катнашында кичә уздыру. |
| 5. Безнең якның халык авыз иҗаты. Бәетләр, җырлар, мәзәкләр. | Махсус әзерләнгән әңгәмә, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, китапханәче белән берлектә кичә әзерләү, буш вакытта халык җырлары тыңлау. Безнең тирәдә чыккан бәет, мәзәкләрне җыю, әби- | Ата-аналар белән берлектә балалар җыйган халык авыз иҗаты үрнәкләрен альбомга туплау. Мызыкаль кичәләрдә катнашу. |

| | | |
|---|---|---|
| | бабайлар белән очрашу. | |
| 6. Милли киемнәр: алъяпкыч. түбәтәй, калфак, читек. җилән, казаки һ.б. | Мәктәп музеенда булган үрнәкләрне карау. Кәгазьдән милли кием үрнәкләрен кисеп карау. татар милли җыр һәм бию ансамбле чыгышын телевидениедән карау, киемнәренә игътибар итү. | Хезмәт укытучысы һәм эти-әниләр белән бергәләп курчаклар өчен милли кием үрнәкләре тегү. Рәсемнәр ясау, милли бизәкләр. «Әбием сандыгы» дигән кичә уздыру. |
| 7. Безнең мәктәптә укыган танылган шәхесләр. | Безнең мәктәпне тәмамлап чыккан танылган шәхесләр белән очрашу. «Сарман» энциклопедиясенә кергән авылдашларыбыз белән танышу. | Очрашуларга газеталар чыгару, очрашудан калган тәэсирләрне иншада чагылдыру, район газетасына мәкалә язу. |
| 8. Безнең мәктәптә укыткан ветеран укытучылар. | Ветеран укытучыларга багышланган альбом төзүдә катнашу, алар белән очрашу уздыру. | Укытучы профессиясе, безнең мәктәпне бетереп, укытучы булып эшләүчеләр турында белешмәләр туплау, альбом төзү. |
| 9. Безнең авылдан чыккан язучылар, газета хезмәткәрләре. | «Сарман» җыентыгына кергән якташыбыз, 9 китап авторы В.Хәйруллина, Н.Гарифҗанова белән очрашу, С.Рафиковның иҗаты белән якыннан танышу. | Газете материалларын туплау. Альбом төзү. Шигырьләр ятлап, кичәдә сойләү. Класстан тыш эшләрдә бу шагыйрьләрнең шигырьләрен файдалану. |
| 10. Ата аналарның эш урыны. Безнең хуҗалык. Аның алдынгы кешеләре. | Авыл җирендә кирәкле профессияләр турында әңгәмә. Хуҗалык эшләре белән танышып бару. Ата-аналарның эш урыннарына экскурсияләр оештыру. Балалардан ата-аналарының эше турында сөйләтү. | Класстан тыш эшләргә, дәресләргә хуҗалык җитәкчеләрен чакыру. Газета битләрендә чыккан материаллар белән танышып бару. Ата-аналарының эшләре турында иншалар язу, рәсемнәр ясау. |
| 11. Безнең авылның һөнәр ияләре. | Чигүче апалар, кәрҗин үрүчеләр. агач эше осталары, бәйләмчеләрне ачыклау. Аларның эшләреннән күргәзмә оештыру. Ә.Газизовнын тәрәзә кашагаларын, | Милли чигү үрнәкләре ясау, мәктәпнең «Оста куллар» түгәрәгенә йөрү. Дәрестән соң буш вакытларда кул эше белән шөгыльләнү. Ата-аналардан ярдәм |

| | | |
|---|---|---|
| | эшләрен фотога төшерү, үзе белән әңгәмә кору. | оештыру. |
| 12. Сарман ягы-кырлар ягы. Безнең район. Аның урамнары, истәлекле урыннары. | Махсус әзерләнгән әңгәмә: Сарман – Татарстан картасында. Район үзәгенә экскурсия, ял паркында, һәйкәлләр янында булу. Сарман районы тарихы белән танышу, класс сәгате уздыру. | Экскурсия нәтиҗәләре буенча фотостенд ясау, класс сәгатьләрендә файдалану. Район тарихы буенча материаллар туплау. |
| 13. Сарман ягы – җыр ягы. Сарманның иҗат кешеләре. | «Сарман» җыентыгына кергән иң күренекле иҗат кешеләре белән танышу. И.Шакиров, З.Сәхәбиева, З.Шәрифуллина, Г.Хәйруллина, Ф.Сафина, В.Әхмәтшин, Д.Гарифуллин, К.Булатова, А.Гыйләҗев һ.б. иҗатына багышланган әңгәмәләр. Мәктәптә Д.Гарифуллин белән очрашу. «Сарман» халык җырын өйрәнү. | Сарман ягында үскән язучыларның китап күргәзмәләрен оештыру, аларның иҗатына багышланган әңгәмәләр уздыру. Шигырьләрен ятлап сөйләү, класстан тыш эшләрдә аларның иҗат үрнәкләрен файдалану. |
| 14. Сарман – нефть табучылар ягы. «Җәлилнефть» һәм Җәлил бистәсе. | Безнең районның җир асты байлыклары турында белешмәләр белән танышу. Районның атаклы нефтьчеләре – «Сарман» энциклопедиясендә. Җәлил бистәсенә багышланган газета материаллары белән танышу. | «Машиналар ни ашый?», «Ягулыкны кем таба?», «Җир мае» сәясәт ясый» темаларына әңгәмә. |
| 15. Сарман икмәге. Алдынгы игенчеләр, терлекчеләр. | Сарманның урак батырлары, кыр батырлары, аларны зурлау, хөрмәтләү, «Уңыш» бәйрәмнәре ничек узуын күзәтеп бару. Сарман уңышында безнең хуҗалыкның, безнең укучыларның өлеше. Хезмәт кешесенә зур хөрмәт | Газета материалларын туплау. «Икмәк булса җыр да була» дигән кичә уздыру. Мәктәптә уңыш бәйрәме уздыру, кызыклы экспонатлар әзерләү, рәсем конкурсында катнашу. «Мин кем булырга |

| | | |
|---|---|---|
| | күрсәтү. | телим». |
| 16. Туган илем – хөр Татарстан. Татарстан картасы, аның районнары. Россия картасындагы урыны. | Махсус әзерләнгән әңгәмә. Тарих кабинетында карта буенча сәяхәт. Татарстан районнары белән танышу. Россиянең үзәгендәге хөр дәүләт булырга омтылучы Республикабыз – карта һәм альбом буенча әңгәмә. | Татарстан турында чыккан альбом, открыткалар җыелмасы булдыру. Иншалар язу. Туган илгә булган хисләрне шигырьләр аша чагылдыру. «Мин яратам сине, Татарстан» җырын өйрәнү. |
| 17. Безнең президентларыбыз. Татарстан гимны, байрагы, туграсы. | Махсус әңгәмә уздыру, татар милләтенең иң күркәм сыйфатларын туплаган кеше булганга күрә, гап-гади авыл егете мондый биеклеккә ирешә алганын күрсәтү. Президентларыбызның республикабызның милли, рухи, сәяси иминлеге гаранты икәнен күрсәтү, гаиләләре белән таныштыру. Дәүләт символлары, аларның тарихы турында әңгәмә. | Президентларыбыз тормышына багышланган материаллар туплау. «Мин президент булсам» дигән темага инша язу. Дәүләт символлары кайда, кайчан, ни өчен файдаланганын күзәтеп бару.<br>Гимнны өйрәнү. |
| 18. Башкалабыз Казан – бөтен дөнья татарлары өчен изге урын. | Башкалабызның истәлекле урыннарына альбом, открыткалар буенча сәяхәт. Махсус әзерләнгән әңгәмәләр. «Вакыт машинасы» дигән уен уздыру (тарихи материаллар буенча). | «Казанның кадерле кичләре» дигән, Казанга багышланган башка җырлар өйрәнү, шигырьләр ятлау. «Казан - башкалам» дигән чара үткәрү. |
| 19. Безнең мәдәни байлыгыбыз. Әдәбият. Сәнгать. Музыка. Газета-журналлар. Радио. Телевидение. Театр. | Әңгәмәләр циклы. Китапханәләргә экскурсия. Татар язучылары, артистлары, журналистлары, рәссамнары турында класста һәм өйдә сөйләшүләр, радио-телевизордан тапшырулар тыңлау. Чаллы курчак театрына культпоход оештыру. Газета-журналларга язылу. | «Сабантуй», «Көмеш кыңгырау», «Ялкын» битләренә күзәтү. Татарстан рәссамнарының әсәрләре репродукцияләрен җыю. Ата-аналар белән берлектә телдән журналлар, тематик кичәләр уздыру. |
| 20. Татарстанның уку йортлары. Фән | Укырга кая кереп була? Кайда кемнәрне әзерлиләр? | «Мин сайлаган уку йорты» дигән темага |

| | | |
|---|---|---|
| казанышлары. Сарман академигы. Безнең авылның фән докторы. | Татарстанның күренекле фән эшлеклеләре. Әңгәмәләр уздыру. Сарман академигы Д.Гарифуллин белән очрашу. Ә.Т.Сибгатуллина биографиясен өйрәнү. | инша язу. Мәктәптә узган очрашулардан алган тәэсирләр белән бүлешү. |
| 21. Безнең бәйрәмнәр. Сөмбелә, Нәүрүз, Сабантуй. Республика көне. | Сөмбелә, Нәүрүз Сабантуй бәйрәмнәренең тарихы, аларның милли характеры. Халкыбызның яңа бәйрәме – Республика көне. Бу бәйрәмнәрнең бездә ничек үтүе, аларда халкыбыз тарихының чагылышы турында әңгәмәләр. | Бу бәйрәмнәрне уздыруда катнашу. «Сабантуй» дигән альбом буенча әңгәмә кору. Мәктәптә узган «Сөмбелә», «Нәүрүз» бәйрәмнәренә әти-әниләрне чакыру. |
| 22. Бабайлар сүзе – акылның күзе. татар халкының милли педагогикасы. | Халык педагогикасы турында, әби-бабайларның әйтүләре, өйрәтүләре булган тәрбия чаралары турында сөйләшү. Балаларның үзләре ишеткәннәрен сөйләтү, аларның дөреслеген тикшерү. | Гаиләдә булган әби-бабайларның тәрбия чаралары белән танышу. Бабайлардан калган бу чараларны җыеп бару. |
| 23. Анам теле – татар теле. | «Туган тел – кухня теле булмасын» - әдәби-музыкаль кичә. Махсус әзерләнгән әңгәмәләр, телдән журнал. | Шигырьләр ятлау, җырлар өйрәнү. Телне ярату турында акыллы сүзләр җыю. |
| 24. Татар халкының милли ризыклары. Кунакчыллык; кунакта, табында үз-үзеңне тоту. | «Тәмле көн» дигән кичә уздыру. Балаларның әниләре, үзләре пешергән милли ризыклары күргәзмәсе. «Чәй бәйрәме» уздыру. «Без табында һәрчак кунак» дигән әңгәмә. Кунакчыллык – татар халкының милли сыйфаты. Ул кунакны һәрчак аягүрә сыйлаган. | Татар халкының ризыкка мөнәсәбәтен, исраф итмәү өчен һәр валчыкны җыюы кебек сыйфатларына игътибар итеп тору. Табында Үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, аңа карата халык тәрбиясе кагыйдәләрен искә төшерү. Чәй, ризык, табын, кунак һәм кунакчыллык турында шигырьләр уку. |
| 25. Чит илдәге яшьтәшемә Татарстан турында мин нәрсә сөйләр | Туган авыл, туган як, Татарстан турында без ниләр белдек? Кабатлау. Горурлык хисе, ярату, аны | Кабатлауга йомгак итеп иншалар язу, конкурс уздыру. «Туган ягым – яшел бишек» дигән |

| | | |
|---|---|---|
| идем? | сакларга әзерлек – яшь гражданинның рухи йөзе. «Милли аң – туган тел аерылгысыз» дигән темага әңгәмә. | темага чит илдәге дустыма адресы белән рәсем ясау. |
| 26. «Җырлыйм илем турында» - әдәби-музыкаль кичә. | Татарстан турында җырлар, шигырьләр, милли киемнәр белән чыгышлар, биюләр оештыру. | Ата-аналарны кичәгә чакыру. Кичәгә әзерләнгәндә аларның ярдәменә таяну. |

**Проект буенча эшләү түбәндәге нәтиҗәләрне бирер дип көтелә:**

1. Балаларның класстан тыш эшләргә, өстәмә биремнәргә карашы үзгәрер.
2. Әти-әниләр һәм балалар арасындагы элемтә көчәер.
3. Укучыларның Татарстан тарихыннан белемнәре тирәнәер.
4. Балалар “Интернет челтәре буш вакытны уздыру өчен шәп” дигән фикеренә “Интернеттан бик күп файдалы мәгълүмат алырга мөмкин” дигән уй өстәлер.
5. Гаиләләрнең шәҗәрәләре төзелеп, уку кабинетында күргәзмә стенд ясалыр.
6. Авыл, елга, тау һ.б. исемнәре турында докладлар әзерләнер.
7. Халык бәйрәмнәре, башкалабыз Казан турында класстан тыш чаралар уздырылыр.
8. Җыелган материаллардан альбомнар төзелер, мәктәп музее экспонатлар белән баетылыр.

Считаю, что процесс воспитания не должен происходить на расстоянии, от случая к случаю. Это непрерывный процесс, и чем больше общих дел, общения, тем он эффективнее. Воспитывать в учениках сочувствие, понимание – это и вера в ученика, и борьба за его человеческое будущее. Умножать, а не только уважать человека в человеке – цель и пафос моей работы.